КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 гыйнвар г.Казань № 30

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган, Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез массакүләм тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм туклану чыгымнарын каплау турында» 2022 ел, 30 апрель, 406 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган, Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез массакүләм тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм туклану чыгымнарын каплау турында» 2022 ел, 30 апрель, 406 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел,

22 август, 883 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм аларның туклану чыгымнарын каплау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның хокукларын яклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның вакытлыча социаль-көнкүреш шартларын оештыру буенча вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын билгеләргә.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның вакытлыча социаль-көнкүреш шартларын булдыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бу карарга теркәлгән Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар өчен

Татарстан Республикасы территориясендә оештырылган вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары исемлеген (карарга теркәлә) расларга.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына кушымтада күрсәтелгән форма буенча торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктында (пунктларында) булган затларның исәбен алып баруны һәм исемлекләрен формалаштыруны һәм әлеге исемлекләрне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм тукландыру өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан тотылган чыгымнарны каплау максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына финанслар белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 5 апрелендәге 591 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 5 апрелендәге 591 номерлы карары) белән расланган Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм тукландыру өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан тотылган чыгымнарны каплау максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына финанслар белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләренең кушымтасында бирелгән форма буенча җыелма исемлек төзүне, әлеге исемлекне Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерүне һәм аны алга таба Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгына тапшыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне тәэмин итәргә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән Россия Федерациясе гражданнары, чит ил

гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары урнаштырылган оешмаларның чыгымнарын каплау, вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында затларның факттагы тору көннәре саныннан чыгып, тәүлеккә бер кешегә 1 328 сумга кадәр күләмдә (вакытлыча урнаштыру өчен тәүлеккә бер кешегә 913 сумга кадәр һәм туклану өчен тәүлеккә бер кешегә 415 сумга кадәр чыгымнарны кертеп) башкарыла;

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча урнаштыру һәм аларның туклану чыгымнарын каплау Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 5 апрелендәге 591 номерлы карары нигезендә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган, Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез массакүләм тәртиптә килгән Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар өчен Татарстан Республикасы территориясендә оештырылган вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары исемлеген яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Кичектергесез массаүләм тәртиптә килгән һәм вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктында (пунктларында) булган затлар исемлеге формасында:

нумерация башисемендә «карары белән расланган» сүзләрен «карарына кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

исемендә «Кичектергесез массаүләм тәртиптә килгән затлар» сүзләрен «Торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән затлар» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 30 апрель, 406 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 21 гыйнвар, 30 нчы
карары редакциясендә)

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар өчен Татарстан Республикасы территориясендә оештырылган вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары исемлеге

| Т/с | Вакытлыча урнаштыру һәм туклану пункты урнашкан муниципаль берәмлек исеме | Вакытлыча урнаштыру һәм туклану пункты урнашкан оешма исеме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Казан шәһәре | Шәхси эшмәкәр Әбүшахманова Гөлнара Рафаил кызы («Второй Дом» кунакханәсе) |
| 2. | | «КВАРТ» Кама-Идел резинотехника акционерлык җәмгыяте» акционерлык җәмгыяте («КВАРТ» акционерлык җәмгыятенең кунакханә-торак комплексы) |
| 3. | | «Ливадия-Татарстан» шифаханәләр һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе |
| 4. | | «Экспресс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте («Экспресс» хостеле) |
| 5. | | Шәхси эшмәкәр Гарбуз Михаил Иосифович («Отель Стрела») |
| 6. | Алабуга муниципаль районы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (Алабуга институты (филиал)) |
| 7. | Зеленодольск муниципаль районы | «Васильевский» шифаханәләр һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе |
| 8. | Лаеш муниципаль районы | «Санта» шифаханәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 9. | | «Санта Регина» шифаханәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 10. | Яр Чаллы шәһәре | «КАМАЗжилбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 11. | | «Жемчужина» шифаханәләр һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе |